| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТИМЯШЕВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТИМӘШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

**2022 елның 1 июне** **№ 11**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 40 номерлы карары белән расланганТимәш авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 40 номерлы карары белән расланган Тимәш авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктның 3 пунктчасында «,акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы,33 адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru)«Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авылҗирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сираев